
# Әти-әниләр сезнең өчен

Тәрбияви киңәшләр



- Баланың үз яшеннән кечерәйтеп карамагыз.
- Кечкенә бала өлкәннәрне елап җиңмәсен.



- Бала үзе эшли алган эшне аның өчен эшләмәгез.
- Баланың колына әверелмәгез.



- Баланың кылган гамәленә тиз арада аңлату тәлап итмә,уйлау өчен вакыт калдыр.
- Бала еш үзе дә аңламаган гамәлләр кыла.


- Балага даими ышаныч күрсәтегез.
- Ашыгып куркып уйламыйча җавап бирү баланы ялганчы ясый.

- Баланың курку,борчылулары өчен артык кайгырмагыз.
- Әти-әни куркуы баланың тагын да ышанычсызлыгын арттыра.

- Эшли алмаслыкны вәгъдә итмәгез
- Ялганчы булып күренмәгез, ышанычны югалтырсыз.

- Балага артык каныгу белән мавыкмагыз.
- Сезнең шелтәләрегезне, кисәтүләрегезне ул ишетми торганга әверелмәсен.

- Ясаган ялгыш гамәлләр өчен артык борчылмагыз.
- Сезнең кебек үк бала уз хаталарында өйрәнә.



- Кечкенәдән бала хыялый була, фантазиясен сүндермәгез.
- Дөньяны танып белүдә балага юл күрсәтегез,ләкин эшләп бирмәгез.



- Чит кешеләр барында балага кисәтү ясамагыз.
- Күзгә-күз калып сөйләшү,аңлашу кычкырудан мең өлеш артык.

- Баланың бер генә соравын да җавапсыз калдырмагыз.
- Сез җавап бирмәгән сорауларга ул җавапны читтән,урамнан, иптәшләреннән ала.

- Бала белән әти-әни арасында ышану,ярату бары уңай эмоцияләр генә өстенлек итсен.



- Бала белән бик аз вакыт аралыгында аралашып та файдасы зур булырга мөмкин,ләкин киресе зыянлы.



- Көч кулланып баланы җиңәргә тырышу һич ярамый!
- Бала күңеленә җәрәхәт салма.

- Яшүсмер чорның иң катлаулы,җаваплы чор булуын онытмагыз.
- Бу чорда бала әти-әнисенең эшенә, сүзенә,кылган гамәлләренә аеруча игътибарлы:бертөрле әйтеп икенче төрле эшләмәгез.

# Биргән киңәшләргә колак салыгыз!

Игътибарыгыз өчен рәхмәт!